# Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларының IX сыйныф укучыларына ТАТАР ТЕЛЕННӘН бердәм республика тесты

## 0054 нче вариант

## Эшне үтәү өчен күрсәтмә

Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларының 9 нчы сыйныфын тәмамлаучы укучылар өчен, татар теленнән бердәм республика тестына 2 сәгать 30 минут (150 минут) вакыт бирелә. Тест биремнәре 3 бүлектән тора.

**Беренче бүлек**тә 2 тапкыр **тыңланган** текстның кыскача эчтәлеге (изложение) язылa. Ул **2 нче номерлы җавап бланкында** эшләнә.

**Икенче бүлек**не укучылар **үзләре укыган** текстка нигезләнеп башкара. Ул 9 биремнән тора (2-10 биремнәр). 2 – 3 нче биремнәрне үтәгәндә, дөрес җавапны тәкъдим ителгән 4 варианттан сайлап алып, 1 нче номерлы җавап бланкына бер цифр белән язарга кирәк. Бу бланкта 1 нче бирем җавабын язарга тиешле урын буш кала. 4 – 10 нчы биремнәргә җавапларны укучылар мөстәкыйль рәвештә формалаштыралар. Әлеге биремнәргә җаваплар сүз яки цифрлар белән 1 нче номерлы җавап бланкына языла. Ялгышкан очракта, аны пөхтә итеп сызып, янына дөрес җавапны язарга була.

**Өченче бүлектәге** биремне укучылар 2 нче бүлектәге текст буенча башкаралар. Эшли башлаганчы, тәкъдим ителгән (11.1 һәм 11.2) биремнәрнең берсен сайларга һәм үз фикереңне дәлилләп, эзлекле рәвештә киңәйтелгән җавап бирергә кирәк.

Тест биремнәрен үтәгәндә, орфографик сүзлекләрдән файдаланырга рөхсәт ителә.

Караламадагы язулар тикшерелми!

Биремнәрне тәкъдим ителгән эзлеклелектә эшләргә киңәш ителә. Җавап бирергә авырсынган бирем очраса, аны калдырып, башкаларын эшли торыгыз. Вакыт калса, аларга яңадан әйләнеп кайтырсыз.

Үтәлгән биремнәр өчен куелган баллар бергә кушыла. Мөмкин кадәр күбрәк биремгә дөрес җавап биреп, югарырак балл җыярга тырышыгыз.

**Сезгә уңышлар телибез!**

## I бүлек

***Текстны тыңлагыз һәм 1 нче биремне 2 нче номерлы җаваплар бланкында эшләгез. Башта биремнең номерын, аннары изложение текстын языгыз.***

| 1 | Текстны тыңлагыз һәм кыска изложение языгыз. Текстны тыңлагач, микротемаларны билгеләгез. Тулы текстның һәм андагы микротемаларның төп эчтәлеген бирергә кирәклеген истә тотып эшләгез. Изложениенең күләме **50 сүздән** ким булмаска тиеш. Изложениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.

## II бүлек

***Текстны укыгыз һәм 2-10 нчы биремнәрне үтәгез.***

### Моңлы тел

1) Безнең телебез – бик моңлы тел. 2) Борынгы татар халык җырларын тыңлаганда, моң, безнең күңелләребезне айкап, тирән уйларга, кичерешләргә сала. 3) Шушы моң халыкның хәтер кылларына кагыла да үткәннәрне бүгенге белән тоташтыра.

4) Телнең нечкәлекләрен белү өчен, аны һәркөн куллану кирәк. 5) Әгәр син үз телеңне белмисең икән, үз халкыңның мәдәниятен, аның рухи байлыгын үзләштерә алмыйсың. 6) Моңа мисал итеп К.Г.Паустовскийның туган тел турында әйткән сүзләрен искә алу белән чикләнәм: "Үз илеңә булган мәхәббәтне үз телеңә булган мәхәббәттән башка күз алдына китереп булмый".

7) Әйе, туган телне белмәү – наданлык. 8) Үз телеңне, үз мәдәниятеңне белмәү, бүтәнгә табыну, аларны үз мәдәниятеңнән өстен кую кебек зарарлы караш китереп чыгарырга мөмкин. 9) Кайвакыт ачык тәрәзә аша үсмерләрнең урам бетереп, шаулап-гөрләп барганнарын ишетергә туры килә. 10) Ирексездән ишетелгән сүзләрдән колаклар кызара. 11) Гүя урам буйлап бу үсмерләр кешеләрнең йөзләренә пычрак атып йөриләр. 12) Бу нәрсә, минемчә, телгә һәм үз халкыңа мәхәббәт булмаудан килеп чыга. 13) Әгәр без халкыбызның гасырлар буе тупланып килгән рухи байлыгын аңларга, үзләштерергә телибез икән, иң беренче туган телебезне белергә тиешбез.14) Телне ярату өчен, аны аңлау, я булмаса аңларга тырышу кирәк.

15) Тел – халык күңеленең кыңгыравы. 16) Ә кыңгырау – кагылмасаң чыңламый. 17) Әйдәгез, шушы кыңгырауны ешрак кагыйк! 18) Ул тутыкмасын, тавышы гел саф, гел матур булсын, аның моңы еракка яңгырасын! (*Фәнис Яруллиннан*)

***Фәнис Гатаулла улы Яруллин*** *(1938-2011) – Татарстанның халык шагыйре, ТАССРның ат казанган мәдәният хезмәткәре. 1958 нче елдан урын өстендә булуына карамасатан, заманыбызның сулышын тоеп яшәүне*

*белдергән һәм тормышка соклану, аңа ышану хисләре белән сугарылган, төрле жанрда язылган бик күп әсәрләр авторы.*

***2 – 10 нчы биремнәрнең җавабы сүз яки цифр булырга мөмкин. Башта җавапны текстта күрсәтегез, соңыннан 1 нче номерлы бланкка <u>буш ара калдырмыйча, тыныш билгеләрсез, башка өстәмә символларсыз</u> күчереп алыгыз. Һәр хәрефне һәм санны, бланктагы үрнәктә күрсәтелгәнчә, аерым шакмакка языгыз.***

**2** **Сингармонизмга буйсынмаган сүз кулланылган җөмләнең номерын күрсәтегез.**

1) Телнең нечкәлекләрен белү өчен, аны һәркөн куллану кирәк.

2) Әгәр син үз телеңне белмисең икән, үз халкыңның мәдәниятен, аның рухи байлыгын үзләштерә алмыйсың.

3) Әйе, туган телне белмәү – наданлык.

4) Тел – халык күңеленең кыңгыравы.

Җавап:________________.

**3** **Үзара синоним булган сүзләр кулланылган җөмләнең номерын күрсәтегез.**

1) Кайвакыт ачык тәрәзә аша үсмерләрнең урам бетереп, шаулап-гөрләп барганнарын ишетергә туры килә.

2) Тел – халык күңеленең кыңгыравы.

3) Гүя урам буйлап бу үсмерләр кешеләрнең йөзләренә пычрак атып йөриләр.

4) Ул тутыкмасын, тавышы гел саф, гел матур булсын, аның моңы еракка яңгырасын!

Җавап:________________.

**4** **1-3 нче җөмләләрдән тиңдәш хәбәрләре булган җөмләнең номерын языгыз.**

Җавап: ________________ .

**5** **16-18 нче җөмләләрнең кайсында чагыштыру дәрәҗәсендәге рәвеш бар?**

Җавап: ________________ .

**6** **1-3 нче җөмләләрдән үзара антоним булган сүзләр кергән җөмлә номерын табып языгыз.**

Җавап: ________________ .

**7** **9-11 нче җөмләләрдән бәйлекне күчереп языгыз.**

Җавап: ________________ .

**8** **16-18 нче җөмләләрдән тезмә кушма җөмләнең номерын языгыз.**
Җавап: ________________.

**9** **Түбәндәге җөймләдә барлык тыныш билгеләре номерланган.** ***Кереш сүз*** **янында куелган тыныш билгеләренең номерларын языгыз.**
Бу нәрсә[1], минемчә[2], телгә һәм үз халкыңа мәхәббәт булмаудан килеп чыга;[3] әгәр без халкыбызның гасырлар буе тупланып килгән рухи байлыгын аңларга[4], үзләштерергә телибез икән[5], иң беренче туган телебезне белергә тиешбез[6].
Җавап: ________________ .

**10** Текст **нинди стильдә** язылган?.
Җавап: ________________ .

***Барлык җавапларны, тестны үтәү өчен күрсәтмәдә әйтелгән тәртиптә, 1 нче номерлы бланкка күчереп язарга онытмагыз.***

**III бүлек**

***2 нче бүлектә укылган текстны файдаланып, 11.1 һәм 11.2 нче биремнәрнең <u>бары тик берсен генә сайлап алып</u>, 2 нче номерлы бланкта биремне үтәгез. Яза башлар алдыннан сайланган биремнең номерын күрсәтегез.***

**11.1. "Тел – халык күңеленең кыңгыравы. Ул тутыкмасын, тавышы гел саф, гел матур булсын, аның моңы еракка яңгырасын!"** җөмләләрендә әйтелгән фикерләрне сез ничек аңлыйсыз? Шулар турында языгыз. Фикерегезне раслау өчен, укылган тексттан **2 мисал** китерегез. Файдаланган җөмләләрнең номерларын языгыз яки тексттан цитата китерегез.

Сочинениенең күләме **50 сүздән** дә ким булмаска тиеш.

Сочинениене чиста һәм таныrлык итеп языгыз.

Укылган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый.

Бирелгән текстны күчереп яисә аның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган өчен ноль балл куела.

**11.2. "Туган телем- иркә гөлем, киңдер сиңа күңел түрем", -** диелә халык мәкалендә. Бу мәкальнең мәгънәсен ничек аңлыйсыз. Фикерегезне раслау өчен, укылган тексттан **1 мисал**, үзегезнең тормыш тәҗрибәсеннән **1 мисал** китерегез.

Сочинениенең күләме **50 сүздән** дә ким булмаска тиеш.

Сочинениене чиста һәм таныrлык итеп языгыз.

Укылган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый.

Бирелгән текстны күчереп яисә аның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган өчен ноль балл куела.